**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

## Казан шәһәрендәге фаҗигале вакыйгалар белән бәйле рәвештә матәм көне игълан итү турында

2015 елның 11 мартында Казан шәһәрендә «Адмирал» сәүдә үзәгендәге янгын нәтиҗәсендә һәлак булганнар турында авыр кайгы белдереп, аларның туганнары һәм якыннарының хәсрәтен уртаклашып, **карар бирәм:**

1. 2015 елның 14 мартын Татарстан Республикасында матәм көне дип игълан итәргә.

2. Матәм көнендә Татарстан Республикасының бөтен территориясендә Татарстан Республикасы Дәүләт флагларын түбәнрәк төшерергә.

3. Телерадиокомпанияләргә һәм мәдәният учреждениеләренә матәм көнендә күңел ачу тапшыруларын һәм чараларын үткәрмәүне тәкъдим итәргә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына янгында һәлак булганнарның гаиләләренә һәм зыян күрүчеләргә ярдәм итү буенча тәкъдимнәр әзерләргә.

5. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы
Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан,Кремль
2015 ел, 13 март
№ ПУ-282